# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Минзәлә муниципаль районы Кадрәк авыл җирлегенең
Яңа Тәкермән торак пунктында
2024 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында

**29.11.2023 ел** **№ 1**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 № 131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 №45-ЗРТ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Минзәлә муниципаль районы Кадрәк авыл җирлегенең Яңа Тәкермән торак пунктында гражданнар җыены

**КАРАР ЧЫГАРДЫ:**

1. Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Кадрәк авыл җирлегенең Яңа Тәкермән торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчедән 2024 елда 2500 сум күләмендә үзсалым кертергә, 1 төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышында катнашучылар, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан, армиядә хезмәт итүчеләр, мобилизацияләнгәннәр һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш
2. Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрергә:

*1) Яңа Тәкермән торак пунктында балалар мәйданчыгы урнаштыру (килешү буенча хезмәтләр өчен түләү);*
*2) Яңа Тәкермән торак пунктының су күтәрү манарасын һәм суүткәргеч челтәрләрен ремонтлау (материаллар сатып алу, өзеклекләрне бетерү, килешү буенча хезмәтләр өчен түләү);*
*3) Яңа Тәкермән торак пункты зиратының коймасын ремонтлау (проф торбаларны буяу, буяулар, кисточкалар сатып алу, килешү буенча хезмәтләр өчен түләү).*

3. Җыенның нәтиҗәләрен Кәдрәк авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән, халык җыенының нәтиҗәләрен Минзәлә муниципаль районының рәсми сайтында бастырырга(https://menzelinsk.tatarstan.ru/), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгән көннән соң ун көн эчендә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Минзәлә муниципаль районы
Кадрәк авыл җирлеге башлыгы ____________ <u>Х. Х. Нәбиуллин</u>
(имза)